РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«26» июня 2024г. г. Альметьевск № 296

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Әлмәт муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы «Әлмәт муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторлары, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 89 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 103 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 136 номерлы, 2022 елның 5 октябрендәге 166 номерлы, 2022 елның 28 декабрендәге 186 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудитор, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү тәртибендә һәм шартларында:

1.1.1 1 бүлектә:

а) 3 пунктның беренче абзацында «2,28» санын «2,8217» санына алмаштырырга;

б) 4 пунктның беренче абзацында «0,81» санын «1,1412» санына алмаштырырга;

в) 5 пунктның беренче абзацында «1,31» санын «1,6412» санына алмаштырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «1,05» санын «1,3507» санына алмаштырырга;

д) 6.1 пунктының беренче абзацында «0,84» санын «1,1054» санына алмаштырырга;

1.1.2. 2 бүлекнең 8 пунктындагы 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

(сумнарда)

| «Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 39 969 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 36 905 |
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 36 905 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 36 239 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 36 106 |
| Башкарма комитетның аппарат (эшләр идарәчесе) җитәкчесе | 33 574 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе урынбасары | 32 775 |
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 27 446 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (мөдире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 22 650 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 22 650 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек башлыгы | 22 650 |
| Сектор мөдире | 21 051 |
| Баш белгеч | 20 251 |
| Әйдәп баручы белгеч | 19 052 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 17 054» |

1.3. Карарга 3 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы

җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторларының

(сумнарда)

| «Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 40 515 |
| Башлык урынбасары | 36 462 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 36 462 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 32 774 |
| Контроль-хисап палатасы аудиторы | 27 444» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны районның законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов

СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА